**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәре
(муниципаль тур, 2018-2019 уку елы) 7 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты- 120 минут
Максималь балл – 40 балл**

**I. Әдәбият теориясенә караган биремнәр (12 балл).**

1. Поэма жанрына хас үзенчәлекләрне Һ. Такташның “Мокамай” поэмасы мисалында аңлатыгыз (10 балл).
2. Поэма кем исеменнән сөйләнелә? Бер сүз яки сүзтезмә белән язып куегыз (2 балл).

**II. Әдәби иҗатка караган биремнәр (18 балл).**

1. Чистай районы Яуширмә авылы – Чистай – Оренбург – Берлин – Анкара – Истанбул. Әлеге урыннар кайсы әдип исеме белән бәйләнгән? (3 балл).
2. Бу әдип әдәбиятның кайсы төрләрендә иҗат итә? Бер җөмлә белән язып куегыз (3 балл).
3. Г.Исхакыйның “Җан Баевич” әсәрендә автор нинди сыйфатлардан көлә? Үз фикерегезне дәлилләп языгыз (6 балл).
4. Әлеге әсәрдә Шакирҗанга хас сыйфатларны капма-каршы ике төркемгә – уңай һәм тискәре сыйфатларга бүлеп языгыз (6 балл).

**III. Иҗади эш (10 балл).**

Түбәндәге сүзләрне танылган шагыйрьнең әсәреннән бер строфалык шигырь итеп формалаштырыгыз: *ыштансыз, белән, әкияттәге, үрмәләп, кебек, идек, бергәләп, каен, ике, танышып, бала, дөнья, башларына, ике, йөргән, малай.*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәре
(муниципаль тур, 2018-2019 уку елы) 8 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты- 180 минут
Максималь балл – 42 балл**

**IV. Әдәбият теориясенә караган биремнәр (12 балл).**

3. Трагедия жанрына хас үзенчәлекләрне Ф.Бурнашның “Таһир-Зөһрә” әсәре мисалында аңлатыгыз. Үз фикерегезне дәлилләп языгыз (10 балл).
4. Әсәрдәге Таһир белән Зөһрәгә бәйле вакыйгалар ничек тәмамлана? Бер сүз яки сүзтезмә белән язып куегыз (2 балл).

**V. Әдәби иҗатка караган биремнәр (20 балл).**

1. Пенза өлкәсе Аккүл авылы – Казан – Орнебург – Ташкент. Әлеге урыннар кайсы әдип исеме белән бәйләнгән? (3 балл).

2. Бу әдип әдәбиятның кайсы төрләрендә иҗат итә? Бер җөмлә белән язып куегыз (3 балл).

3. К.Тинчуринның “Сүнгән йолдызлар” әсәрендә автор нинди сыйфатларны фаҗига итеп күтәрә? Санап чыгыгыз (4 балл).

4. Әлеге әсәрдә Исмәгыйль күргән төш символик мәгънәгә ия, аны әсәр сюжеты белән бәйләп аңлатыгыз. Үз фикерегезне дәлилләп языгыз (10 балл).

**VI. Иҗади эш (10 балл).**

Түбәндәге сүзләрне танылган шагыйрьнең әсәреннән бер строфалык шигырь итеп формалаштырыгыз: *усал, үзе, шикелле, матур, кебек, үзе, дә, сөйкемле, бер, үзе, түгел, үзе, болай, усал.*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәре**
**(муниципаль тур, 2018-2019 уку елы) 9 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты- 180 минут**
**Максималь балл – 48 балл**

**VII. Әдәбият теориясенә караган биремнәр (12 балл).**

5. Хикмәт жанрына хас үзенчәлекләрне М.Колый хикмәтләре мисалында аңлатыгыз. Үз фикерегезне дәлилләп языгыз (10 балл).

6. Хикмәтләр кем исеменнән сөйләнелә? Бер сүз яки сүзтезмә белән язып куегыз (2 балл).

**VIII. Әдәби иҗатка караган биремнәр (26 балл).**

1. Чирмешән районы Яңа Кади авылы – Каргалы – Бохара – Сәмәрканд – Чистай өязе Исләй авылы. Әлеге урыннар кайсы әдип исеме белән бәйләнгән? (3 балл).

2. Бу әдип әдәбиятның кайсы төрендә иҗат итә? Бер җөмлә белән язып куегыз (3 балл).

3. Габдерәхим Утыз Имәнинең лирик героена нинди сыйфатлар хас? Үз фикерегезне дәлилләп языгыз (10 балл).

4. Аның әсәрләрендә мәгърифәткә бәйле нинди фикерләр урын ала? Үз фикерегезне дәлилләп языгыз (10 балл).

**IX. Иҗади эш (10 балл).**

Түбәндәге сүзләрне танылган әдипнең әсәреннән өзек итеп формалаштырыгыз: *яуды, имди, кебек, энҗе-мәрҗән, итәгемә, мин, җыйдым, җиргә, яңгыр, аларны*.

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәре (муниципаль тур, 2018-2019 уку елы) 10 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты- 180 минут**
**Максималь балл – 48 балл**

**X. Әдәбият теориясенә караган биремнәр (12 балл).**

1. Фәлсәфи шигырьгә хас үзенчәлекләрне Дәрдемәнд иҗаты мисалында аңлатыгыз. Үз фикерегезне дәлилләп язгыз (10 балл).
2. Аның шигырьләре кем исеменнән сөйләнелә? Бер сүз яки сүзтезмә белән язып куегыз (2 балл).

**XI. Әдәби иҗатка караган биремнәр (26 балл).**

1. Оренбург өлкәсе Акман авылы – Казан – Әстерхан – Уфа. Әлеге урыннар кайсы әдип исеме белән бәйләнгән? (3 балл).
2. Бу әдип әдәбиятның кайсы төрләрендә иҗат итә? Бер җөмлә белән язып куегыз (3 балл).
3. С.Рәмиевнең лирик героена нинди сыйфатлар хас? (10 балл).
4. С.Рәмиевнең әсәрләрендә үз чорына хас нинди фикерләр урын ала? (10 балл).

**XII. Иҗади эш (10 балл).**

Түбәндәге сүзләрне танылган шагыйрьнең әсәреннән бер строфалык шигырь итеп формалаштырыгыз: *йоклый, уянам, кебек, таң, бер, уйланам, вакыты, тиле, татар, мин, уянам, тик, йокысыз, да, үзем*.

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәре (муниципаль тур, 2018-2019 уку елы) 11 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты- 180 минут**
**Максималь балл – 48 балл**

**XIII. Әдәбият теориясенә караган биремнәр (12 балл).**

1. Повесть жанрына хас үзенчәлекләрне А.Гыйләҗевның “Әтәч менгән читәнгә” әсәре мисалында аңлатыгыз. Үз фикерегезне дәлилләп язгыз (10 балл).
2. Әсәрдә дуслыкны, яшәү кыйммәтләрен символлаштырган образны

язып куегыз  (2 балл).

**XIV.  Әдәби иҗатка караган биремнәр (26 балл).**

1. Аксубай районы Иске Кармәт авылы – Тобол губернасы – Уфа – Казан – Покровка. Әлеге урыннар кайсы әдип исеме белән бәйләнгән? (3 балл).

2. Бу әдип әдәбиятның кайсы төрендә иҗат итә? Бер җөмлә белән язып куегыз (3 балл).

3. Х.Туфанның лирик героена нинди сыйфатлар хас? Үз фикерегезне дәлилләп языгыз (10  балл).

4. Х.Туфанның иҗатына үз чорына хас нинди сыйфатлар хас? Үз фикерегезне дәлилләп языгыз (10 балл).

**XV.   Иҗади эш (10 балл).**

Түбәндәге сүзләрне Х.Туфанның танылган әсәреннән бер строфалык шигырь итеп формалаштырыгыз: *иде, сары, күңелсез, иде, көз, каеннар, кыраулы, иде, җирнең, астралар, шушындый, гөлләр, чагы*.